Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз алтынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

23 ноябрь, 2023 ел № 271

2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Питрәч муниципаль районы социаль-икътисадый үсеш фаразы турында

Район икътисадын тотрыклыландыру һәм алга таба үстерү, муниципаль милекне файдалануның нәтиҗәлелеге, шулай ук халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итә торган шартлар формалаштыру максатларында «Питрәч муниципаль районы 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. 2023 елда Питрәч муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең башлангыч нәтиҗәләре турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Кушымта нигезендә, Питрәч муниципаль районының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын хупларга.

3. Тәкъдим итәргә:

- Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына, барлык милек формасындагы предприятие һәм оешма җитәкчеләренә 2024 елга, 2025 һәм 2026 елларның план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән тиешле чаралар күрергә;

- Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлегенә квартал саен 2024 елга фаразны тормышка ашыру мониторингын тормышка ашырырга, мониторинг нәтиҗәләрен Питрәч муниципаль районы Советына җибәрергә.

4. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының икътисади үсеш, бюджет, салымнар һәм финанслар мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

Питрәч муниципаль районы
Советы карарына кушымта
23 ноябрь, 2023 ел № 271

Питрәч муниципаль районының 202 - 2023 елларга социаль-икътисадый үсешенең төп күрсәткечләре
һәм 2024-2026 елларга фараз

| Показатели | **2021 ел хисап** | **2022 ел хисап** | **2023 ел бәяләү** | Фараз | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| **Макроикътисади күрсәткечләр** | | | | | | |
| 1. Тулаем территориаль продукт, млн. сум. | 18342,7 | 22922,6 | 23358,9 | 24850,6 | 26414,6 | 28104,2 |
| 2. «Җитештерүче һәм эшкәртүче сәнәгать» икътисади эшчәнлекнең номумроссия төрләр классификаторы (ОКВЭД) буенча үзе җитештергән товарлар йөкләтелде, млн. сум. | 4518,4 | 5044,8 | 5194,9 | 5424,8 | 5794,2 | 6188,9 |
| 3. Инвестицияләр күләме (төп капиталга) һәр елның гамәлдәге бәяләрендә, млн. сум. | 19721,4 | 21656,6 | 21978,3 | 23883,7 | 25956,3 | 28290,6 |
| 4. Ваклап сату товар әйләнеше, млн. сум. | 4770,98 | 6142,8 | 6740,0 | 7359,6 | 7944,7 | 8584,7 |
| 5. Хезмәт хакы фонды, млн. сум. | 3396,9 | 4213,2 | 4634,5 | 5005,2 | 5380,6 | 5784,2 |
| 6. Даими халык саны (уртача еллык), мең кеше. | 51,5 | 63,93 | 65,0 | 66,2 | 67,0 | 67,7 |
| **Тормыш дәрәҗәсе** | | | | | | |
| 1. Җан башына акчалата керем, сум. | 23749,1 | 28235,4 | 29364,8 | 30744,9 | 29254,9 | 27537,4 |
| 2. Уртача айлык хезмәт хакы (бер елга уртача). | 37508,7 | 43019,1 | 47323,6 | 51040,7 | 54701,4 | 57761,1 |
| 3. Пенсиянең уртача күләме, аена сумнарда | 14179,6 | 16816,5 | 17825,5 | 19162,4 | 20024,7 | 20825,7 |
| 4. Үз керемнәре белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе, % | 48,7 | 46,6 | 46,9 | 47,3 | 47,5 | 48,0 |
| 5. Финанслауның барлык чыганаклары исәбеннән торак йортларны файдалануга кертү, кв.м | 202380 | 239834 | 230000 | 230000 | 230000 | 230000 |
| **Агросәнәгать комплексы** | | | | | | |
| Авыл хуҗалыгының тулаем продукциясе гамәлдәге бәяләрдә, млн. сум. | 4803,5 | 5426 | 5616,4 | 5784,89 | 6074,13 | 6377,83 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | | | | | | |
| - ашлык (эшкәртелгәннән соңгы авырлыкта), мең тонна | 37,979 | 102,67 | 72,1 | 75,7 | 79,49 | 83,46 |
| - бәрәңге, мең тонна | 0,045 | 2,807 | 0,035 | 0,036 | 0,038 | 0,040 |
| - терлек һәм кош (тере авырлыкта), мең тонна | 34253 | 34461 | 34465 | 34480 | 34500 | 34800 |
| - сөт, мең тонна | 24792 | 25006 | 26250 | 27000 | 27900 | 28500 |
| - йомырка, млн. данә | 40,17 | 38,3 | 38 | 38,2 | 38,5 | 39 |